ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона, Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районы территориясендә төзелгән «Зеленая Долина» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары булып торучы оешмалар транспорт чарасын исәпкә куйган вакыттан алып 10 ел дәвамында салым салынудан азат ителә.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан

Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1; 2012, № 6 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**Махсус икътисадый зоналар резидентлары булып торучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында**»;

2) 1 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона, Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районы территориясендә төзелгән «Зеленая Долина» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары булып торучы оешмалар (алга таба – оешмалар-резидентлар) өчен махсус икътисадый зона территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын түбәндәге күләмдә билгеләргә:»;

б) дүртенче абзацта «(2017 – 2020 елларда 12,5 процент)» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацы (әлеге Закон редакциясендә) һәм «Махсус икътисадый зоналар резидентлары булып торучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлешенең беренче абзацы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2025 елның 25 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 90-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН